МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

08.07.2025 Казан ш. № 409-пр

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 05.04.2023 № 225-пр боерыгы белән расланган Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Федераль законнардагы үзгәрешләргә бәйле боерам:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 05.04.2023 № 225-пр боерыгы белән расланган Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары А.И.Галиевка йөкләргә.

**Министр** **А.Р.Кадыйров**

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының
08.07.2025 № 409-пр
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 05.04.2023 № 225-пр боерыгы белән расланган Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелгән үзгәрешләр

2 бүлектә:

2.8.2 пунктның 2 подпунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) ясаласы җир кишәрлеге РФ ҖК $39^{16}$ статьясының 1 - 13, $14^{1}$ - 19, 22 һәм 23 подпунктларында күрсәтелгән нигезләр буенча гариза бирүчегә бирелә алмый;»;

3 бүлектә:

3.6.2.1 пунктның икенче абзацын «шәхси кабинетта» сүзләре алдыннан «Бердәм порталдагы» сүзләре белән тулыландырырга;

3.6.2.2 пунктта унөченче абзацны көчен югалткан дип танырга;

3.6.3 пунктта:

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта документларны теркәмичә генә, Бүлек белгече документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган сәбәпләрне телдән аңлатып, гариза бирүчегә кайтара. Гариза бирүче таләбе буенча документларны кабул итүдән баш тарту язмача әзерләнә.»;

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Административ процедуралар башкаруның нәтиҗәсе: карау өчен кабул ителгән документлар комплекты яки документларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен телдән (язмача) аңлату, гариза бирүчегә кайтарылган документлар.»;

3.9.9 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.9.9. Бүлек белгече күрсәтелгән проектлар буенча кимчелекләр бәян ителгән хокук идарәсе бәяләмәсен алган очракта, булган кимчелекләрне бетерә һәм килештерү турында карар проектын яисә баш тарту турында карар проектын килештерү өчен кабаттан хокук идарәсе башлыгына юллый.»;

Регламентка кушымтаның (белешмәлек) «Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре миинстрлыгы» таблицасында «Җир ресурслары идарәсе башлыгы» юлын төшереп калдырырга.